КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 декабрь г.Казань № 1362

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 31 август, 793 нче карары белән расланган 2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыру кысаларында 2021 елда федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджетара трансфертлар бирү буенча Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына мәҗбүри медицина иминләштерүе буенча иминләштерелгән, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) һәм (яисә) авыруга карата шик белән затларга медицина ярдәме күрсәтүне өстәмә финанс белән тәэмин итүгә бирелә торган максатчан билгеләнеше булган башка бюджетара трансферттан файдалану тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2021 елда территориаль мәҗбүри медицина иминияте программаларын тормышка ашыру кысаларында мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелгән, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) белән авыручы һәм (яки) аның белән авыруга шик булган затларга медицина ярдәме күрсәтүне өстәмә финанслар белән белән тәэмин итү өчен тиешле

территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бюджетара трансфертлар бирү буенча Россия Федерациясе субъектларының һәм Байконур шәһәренең чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү максатларында, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондының бюджет ассигнованиеләре торган Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына һәм Байконур шәһәре бюджетына федераль бюджеттан максатчан билгеләнешкә ия башка бюджетара трансферлар бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 ел, 24 октябрь, 2194 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыру кысаларында 2021 елда федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджетара трансфертлар бирү буенча Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына мәҗбүри медицина иминләштерүгә буенча иминләштерелгән, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) һәм (яисә) авыруга карата шик белән затларга медицина ярдәме күрсәтүне өстәмә финанс белән тәэмин итүгә бирелә торган максатчан билгеләнеше булган башка бюджетара трансферттан файдалану тәртибен раслау турында» 2021 ел, 31 август, 793 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 25 ноябрь, 1126 нчы карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) расланган 2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыру кысаларында 2021 елда федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджетара трансфертлар бирү буенча Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына мәҗбүри медицина иминләштерүгә буенча иминләштерелгән, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) һәм (яисә) авыруга карата шик белән затларга медицина ярдәме күрсәтүне өстәмә финанс белән тәэмин итүгә бирелә торган максатчан билгеләнеше булган башка бюджетара трансферттан файдалану тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «2021 елның 1 гыйнварыннан 31 августына кадәрге чорга» сүзләрен «2021 елда» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2021 елның 1 декабреннән соң Татарстан Республикасының мәҗбүри медицина иминияте территориаль программасын эшләү комиссиясе тарафыннан медицина ярдәме өчен түләү тарифларын арттыру буенча карар кабул ителгән очракта, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 7 августындагы 1310 номерлы карары белән расланган 2021 елда территориаль мәҗбүри медицина иминияте программаларын тормышка ашыру кысаларында мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелгән, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) белән авыручы һәм (яки) аның белән авыруга шик булган затларга медицина ярдәме күрсәтүне өстәмә финанслар белән белән тәэмин итү өчен тиешле территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бюджетара трансфертлар бирү

буенча Россия Федерациясе субъектларының һәм Байконур шәһәренең чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү максатларында, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондының бюджет ассигнованиеләре торган Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына һәм Байконур шәһәре бюджетына федераль бюджеттан максатчан билгеләнешкә ия башка бюджетара трансферлар бирү кагыйдәләренең $7^2$ пунктында күрсәтелгән бюджетара трансферт акчасы, аларны алга таба Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә федераль бюджет кеременә күчерү максаты белән, әлеге Кагыйдәләрнең 13 пунктында билгеләнгән күләмдә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин